**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

№ 176-р 25 март 2015 ел

2015 елга гражданнарның кеременең иң чик күрсәткечләрен һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең иң чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган мөлкәт хакын билгеләү методикасы белән салым салынырга тиешле гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 13.07.2007 ел, № 31-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

1. 2015 елга гражданнарны аз керемлеләр дип тану турында Карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрен билгеләү:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче гражданин милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек бәясе бусагасы:

1.1.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен – 1 084 116 сум.;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 1 379 784 сум.;

1.1.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 1 774 008 сум.;

1.1.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 2 365 344 сум.;

1.1.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 2 956 680 сум.;

1.1.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 3 548 016 сум.;

1.1.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 4 139 352 сум.;

1.1.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 4 730 688 сум.

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче гражданин өчен – 7 007,00 сум.;

1.2.2. . Ике кешедән торган гаилә өчен – 4 459, 00 сум.;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 3 822,00 сум.

2. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Нурлат муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе А.К. Габдуллин